ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**27.10.2021**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 2688**

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 25 маендагы «Мәктәпкәчә белем бирү буенча төп гомуми белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына (балалар бакчаларына) балаларны исәпкә кую һәм кабул итү» муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын яңа редакциядә раслау турында» гы 931 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Гаилә кодексына, 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә мәгариф турында» Федераль законга һәм 2010 елның 27 июлендәге «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 210-ФЗ номерлы Федераль законга кертелгән үзгәрешләргә бәйле рәвештә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 25 маендагы «Мәктәпкәчә белем бирү буенча төп гомуми белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына (балалар бакчаларына) балаларны исәпкә кую һәм кабул итү» муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын яңа редакциядә раслау турында» гы 931 номерлы карарына түбәндәгеләрне бәян итеп үзгәрешләр кертергә:

1.1. 1.2 пунктының уналтынчы абзацын түбәндәге редакциядә:

«Бала бертуганнары һәм атасы йә анасы башка булган абыйсы һәм (яисә) сеңлесе укый торган дәүләт яки муниципаль мәгариф оешмаларына мәктәпкәчә белем бирүнең һәм башлангыч гомуми белем бирүнең төп гомуми белем бирү программалары буенча белем алырга өстенлекле кабул ителү хокукына ия»;

1.2. административ регламентның 1.9 пунктында:

РФ Президентының 2003 елның 05 июнендәге «Наркотик чаралар һәм психотроп матдәләр әйләнешен контрольдә тоту органнарында хезмәт турында» 613 номерлы Указын төшереп калдырырга;

«Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының «Төп гомуми белем бирү программалары - мәктәпкәчә белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2013 елның 30 августындагы 1014 номерлы боерыгын» «Россиянең Мәгариф министрлыгының «Төп гомуми белем бирү программалары - мәктәпкәчә белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2020 елның 31 июлендәге 373 номерлы боерыгы»на алмаштырырга;

1.3. административ регламентның 2 бүлеге «Муниципаль хезмәт күрсәтү стандарты»ндагы 2.1 пунктында, 2.3 пунктында, 2.5 пунктында, 2.8 пунктында «Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының «Төп гомуми белем бирү программалары - мәктәпкәчә белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2013 елның 30 августындагы 1014 номерлы боерыгын» «Россиянең Мәгариф министрлыгының «Төп гомуми белем бирү программалары - мәктәпкәчә белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2020 елның 31 июлендәге 373 номерлы боерыгы»на алмаштырырга;

1.4. «Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм сроклары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән электрон формада административ процедураларны үтәү үзенчәлекләре, шулай ук дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләрендә административ процедураларны үтәү үзенчәлекләре» административ регламентының 3 бүлеге исемен «Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм башкару сроклары, аларны башкару тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән электрон формада административ процедураларны башкару үзенчәлекләре, шулай ук күпфункцияле үзәкләрдә административ процедураларны башкару үзенчәлекләре» исеменә алмаштырырга.

2. Зеленодольск муниципаль районы Советы Аппаратының җәмәгатьчелек һәм ММЧ белән элемтә бүлегенә әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында, Интернет челтәрендәге Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru ) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru ) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам

Җитәкче И.Р. Ганиев